РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО
.
422870, С.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С. Крайнов ур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

2023 елның 23 марты 166№

2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50 һәм 51 ст., 85 ст. 8 п. 4 пунктчасы, 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 1 нче кушымта нигезендә 2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын расларга.

2. Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын үтәү өчен кирәкле әзерлек чараларын гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге рәсми www.torgi.gov.ru сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бюджет, салымнар һәм финанс, җирле җыемнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы : А.Ф.Никошин

.

**2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

## 1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. 2023 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

## 2 нче бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2023 елда муниципаль казнадагы һәм Әлки муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар карамагында булмаган муниципаль милек хосусыйлаштырыла.

2.2.Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган муниципаль милек исемлеге:

| т/б № | Милекнең атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдалануга тапшыру елы, (чыккан елы) | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Автотранспорт чарасы Автомашина TAYOTA LAND CRUISER 200 Җиңел Регистрация номеры Р 226 КО 116 VIN JTMHT05J105027464 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56 й. | 2008 | 3,4 квартал |
| 2 | VOLKSWAGEN PASSAT транспорт чарасы теркәү номеры Р 141 НТ 16 VIN WVWZZZ3CZ8P068242 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56 й. | 2007 | 2,3 квартал |
| 3 | Автобус ПАЗ-32053-70 VIN X1M3205CX80008724 Теркәү номеры Р 029 СУ 16 RUS | Әлки районы, Иске Матак авылы, Пролетар ур., 11 й. | 2008 | 2,3 квартал |
| 4 | Торак булмаган бина, 1 кат кирпеч, гомуми мәйданы - 337,4 кв.м., | Әлки районы, Борискино авылы, Яшьләр ур., 40 й. | 1988 | 4 квартал |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Торак булмаган бина, 1 кат кирпеч, гомуми мәйданы - 301,9кв м. | Әлки муниципаль районы, Иске Салман авылы, Үзәк,6 й. | 1973 | 4 квартал |
| 6 | Милек комплексы (Хлебодаровка башлангыч мәктәп бинасы 2 катлы кирпеч, гомуми мәйданы - 1128,4кв.м., 2003 елда төзелгән; - мәктәп котельные, мәйданы - 38,4 кв.м, 2003 елда төзелгән; - Хуҗалык корылмалары, мәйданы - 27,4кв.м, 2006 елда төзелгән) | Әлки муниципаль районы, Хлебодаровка авылы, Зеленая ур., 2 й. | | 3 квартал |
| 7 | Милек комплексы (мәктәп бинасы, 2 катлы кирпеч, мәйданы - 1257,3кв.м, 1981 елда төзелгән; -котельная, мәйданы - 52,7кв.м, 2002 елда төзелгән.) | Әлки муниципаль районы, Татар Чиябашы авылы Җиңү ур., 18 й. | | 4 квартал |
| 8 | Торак булмаган бина, кирпеч, гомуми мәйданы - 198,4 кв.м) | Әлки муниципаль районы, Татар Чиябашы авылы, Җиңү ур., 25 й. | 1998 | 4 квартал |
| 9 | Торак булмаган бина, 1 катлы, кирпеч, гомуми мәйданы - 319,9 кв.м) | Әлки муниципаль районы, Татар Төгәлбәе авылы, Мәктәп урамы, 10 й. | 1996 | 4 квартал |
| 10 | Милек комплексы (мәктәп бинасы, кирпеч, мәйданы-503,6 кв.м, 1995 елда төзелгән); -котельная, мәйданы - 10,2кв.м, 2002 елда төзелгән.) | Әлки районы, Кошки авылы, Мәктәп ур., 10 й. | | 4 квартал |

## 3 нче бүлек. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү муниципаль мөлкәт

3.1. Әлки муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатыннан әлеге фараз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.